СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.07.2018 с. Кильдеево 41-196

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Уставы проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының 16.04.2013 ел, №31-165 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә (№1 кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы проекты буенча килгән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башлыгы Бурдин В. М.;

- эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Н.Н.Левочкина;

Эшче төркем әгъзалары:

- Липатова Галина Леонидовна-Килди балалар бакчасы мөдире;
- Зинонова Татьяна Анатольевна-Килди авыл мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе;
- Лазарева Людмила Анатольевна-Килди ОПС начальнигы.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы проекты буенча 2018 елның 31 июлендә 10.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл мәдәният йортында (Килди авылы, Центральная урамы, 16 йорт) ачык тыңлаулар үткәрергә.

6. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин